**СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

КАРАР

Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы

2020 елның 15 июне № 67-155

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгытау авыл җирлеге” җирле үзидарсенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен , әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаган очракта, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфаны,контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, җирле администрация башлыгы вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны,контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, “Тубылгытау авыл җирлеге”Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгытау авыл җирлеге” җирле үзидарсенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен , әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаган очракта, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибен расларга (Кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда (http:/ / pravo. tatarstan. ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам..

Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмагилов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгытау авыл җирлеге
Советы карарына
2020 елның 15 июненән № 67-155

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгытау авыл җирлеге” җирле үзидарсенең депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен , әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаган очракта, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы “Тубылгытау авыл җирлеге” җирле үзидарә депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына (алга таба – муниципаль вазыйфаны биләүче зат) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба - мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр) турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаган очракта, җаваплылык чараларын (алга таба - җаваплылык чаралары) куллану буенча карар кабул итү процедурасын регламентлый.

2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^{3-1}$ өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфадан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфаны биләү хокукыннан мәхрүм итү белән аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы азат итү;

3) аның вәкаләтләре вакыты беткәнчегә кадәр даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү.;

4) аның вәкаләтләре срогы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советында вазыйфаларны биләүне тыю;

5) даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне вәкаләтләр срогы тәмамланганчы тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсе буларак куллану турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы белән (алга таба-Совет)карала.

Әлеге мәсьәләне карау өчен нигез булып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы $7^3$ өлешендә каралган Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка җаваплылык чараларын куллану турында Советка кергән гаризасы тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет тарафыннан гариза кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка, аңа карата күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә язма рәвештә җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында хәбәр итә.

Совет утырышының урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләп торучы затның утырышка килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы Совет утырышында Советның 2009 елның 28 нче ноябрендә 29-141 нче номерлы карары белән расланган Регламентында билгеләнгән тәртиптә карала (алга таба – Регламент).

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка тапшырылган мәгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәләне караганда, депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче депутатларга мәнфәгатьләр каршылыгы булуы яисә барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу максатларында, мәнфәгатьләр конфликты ягында булган депутат рәислек итүче тарафыннан карар кабул итүдән читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында Карар кабул ителә.

Әлеге карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президенты гаризасында күрсәтелгән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, тигезлек, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, кылынган коррупцион хокук бозу характерын, аның авырлыгын исәпкә алып, шулай ук муниципаль вазыйфа, үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) биләгән зат тарафыннан башкарылган эшләрнең элеккеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәүне исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен бары тик бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан коррупцион хокук бозу турында, бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләренә күрсәтмә булырга, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга шикаять бирү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезләнүе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имзалттырып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар муниципаль вазифаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яки күрсәтелгән зат кул куеп карар кабул итүдән баш тартса, Авыл җирлеге башлыгы тарафыннан акт төзүгә Совет тарафыннан күрсәтелгән затның

җаваплылык чарасын куллану турында карар белән таныштырудан баш тартуы, яки бу карар турында хәбәр итү мөмкинлеге булмау турында акт төзелә.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.